ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 гыйнвар 2019 ел № 153

Муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм аның Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 маддәсенең 3 һәм 4 пунктлары, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы Федераль законның 9.2 маддәсе 7 пунктының 3 пунктчасы, «Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль законның 4 маддәсе 5 бүлегенең 3 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм аның Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләренә муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 елның 26 октябрендәге 6967 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләренә муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 20 мартындагы 1341 нче карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 17 гыйнварындагы
153 нче карарына
кушымта

Муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм аның Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамә

1. бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәне формалаштыру, үзгәртү һәм раслау тәртибе

1. Әлеге нигезнамә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 маддәсенең 3 һәм 4 пунктлары, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы Федераль законның 9.2 маддәсе 7 пунктының 3 пунктчасы, «Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль законның 4 маддәсе 5 бүлегенең 3 пункты нигезендә түбәндәгеләрне билгели:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәне формалаштыру, үзгәртү һәм раслау тәртибен, срокларын;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләмен билгеләү тәртибен һәм срокларын, түбәндәгеләрне кертеп:

- муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнарның база нормативлары һәм аларга төзәтмәләр кертү коэффициентлары нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү һәм раслау;

- муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия күчерү сроклары һәм күләмнәре;

- муниципаль йөкләмә үтәлмәгән булып исәпләнгән очракта, ирешелмәгән (рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышларны исәпкә алып) муниципаль йөкләмә күрсәткечләренә туры килә торган күләмдә субсидияне кире кайтару;

3) муниципаль йөкләмә үтәлешен контрольдә тотуны, аның үтәлеше турындагы хисапны гамәлгә ашыру тәртибе;

4) муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү тәртибе.

2. Муниципаль йөкләмә, чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджетын формалаштыру барышында муниципаль учреждениенең гамәлгә кую документларында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә, әлеге нигезнамәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча Башкарма комитетның тиешле эшчәнлек өлкәсендә кураторлык итүче тармак органы

(алга таба – Башкарма комитетның тармак органы) тарафыннан формалаштырыла.

3. Муниципаль йөкләмә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм (яки) күләмен (эчтәлеген) характерлаучы күрсәткечләр;

2) тиешле хезмәтләрне кулланучылар булып торучы физик һәм (яки) юридик затлар категорияләре;

3) тиешле хезмәтләр күрсәтү тәртибе;

4) Россия Федерациясе законнары белән аларны түләүле нигездә күрсәтү каралган очракларда физик яки юридик затлар тарафыннан тиешле хезмәтләргә түләүнең иң чик бәяләре (тарифлар) яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә Башкарма комитет карары белән билгеләнгән очракларда күрсәтелгән бәяләрне (тарифларны) билгеләү тәртибе;

5) муниципаль йөкләмә үтәлешен контрольдә тоту тәртибе, шул исәптән аны вакытыннан алда туктату шартлары һәм тәртибе;

6) муниципаль йөкләмә үтәлеше турындагы хисапка таләпләр.

4. Муниципаль йөкләмә, шәһәр бюджетын чираттагы финанс елына раслаган очракта – бер елга кадәр срокка яки шәһәр бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына раслаган очракта – өч елга кадәр срокка (бюджет проектын төзегәндә мөмкин булганча төгәллек кертеп) формалаштырыла.

5. Муниципаль учреждениегә ике яки аннан күбрәк муниципаль хезмәткә муниципаль йөкләмә билгеләнгәндә, йөкләмә ике яки аннан күбрәк бүлектән формалаштырыла, аларның һәркайсы һәр муниципаль хезмәт күрсәтүгә карата таләпләрне үз эченә алырга тиеш.

6. Муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр өлешендә муниципаль йөкләмә физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары) нигезендә формалаштырыла, аларны формалаштыру, алып бару һәм раслау Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән исемлеккә (классификаторларга) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне кертү рөхсәт ителми.

7. Чираттагы финанс елына Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан формалаштырылган муниципаль йөкләмә агымдагы елның 1 декабренә кадәр Башкарма комитетның Финанс идарәсе белән килешенергә һәм агымдагы елның 20 декабренә кадәр Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан расланырга тиеш.

8. Муниципаль йөкләмәгә үзгәрешләр кертү Башкарма комитетның тармак органы яки муниципаль учреждение инициативасы буенча муниципаль йөкләмәне яңа редакциядә формалаштыру юлы белән, түбәндәге очраклар барлыкка килгән көннән башлап 20 эш көненнән дә артмаган срокта гамәлгә ашырыла:

1) сыйфат стандартына, муниципаль йөкләмә формалаштыруга нигез булган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелү;

2) муниципаль йөкләмә үтәлеше турындагы хисапны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, муниципаль учреждение тарафыннан тиешле хисап чорында муниципаль йөкләмәдә каралганнан азрак (күбрәк) күләмдә хезмәт күрсәтү факты ачыклану;

3) муниципаль учреждениенең исемен, төп эшчәнлек төрләрен үзгәртү өлешендә муниципаль учреждение уставына үзгәрешләр кертелү;

4) кулланучыларның күрсәтелә торган муниципаль хезмәткә һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү шартларына ихтыяҗы үзгәрү;

5) муниципаль учреждениенең комплектлыгы үзгәрүгә бәйле сан күрсәткечләре үзгәрү;

6) муниципаль йөкләмәдә техник хаталар ачыкланганда.

## 2 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләмен билгеләү тәртибе

9. Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә, Башкарма комитет карары белән раслана.

Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләме Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар, шулай ук муниципаль йөкләмәне үтәүгә бәйле, ләкин норматив чыгымнарга кертелмәгән чыгымнар нигезендә агымдагы елның 1 декабренә кадәр срокка исәпләнә.

Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән яки мондый мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы бүлеп биргән акчалар хисабына муниципаль автономияле учреждение тарафыннан сатып алынган муниципаль мөлкәтне карап тоту чыгымнарын, салым салу объекты буларак тиешле мөлкәт, шул исәптән җир участоклары танылa торган салымнарны түләү чыгымнарын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Муниципаль автономияле учреждениегә гамәлгә куючы тарафыннан беркетелгән яки мондый мөлкәт сатып алу өчен гамәлгә куючы бүлеп биргән акчалар хисабына муниципаль автономияле учреждение тарафыннан сатып алынган күчемсез мөлкәт яки аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт гамәлгә куючының ризалыгы белән арендага бирелгән очракта, гамәлгә куючы тарафыннан мондый мөлкәтне карап тотуны финанс белән тәэмин итү гамәлгә ашырылмый.

10. Муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия күчерү өчен, муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин

итүгә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешү нигез булып тора.

Субсидия күләме муниципаль йөкләмә күрсәткечләре нигезендә исәпләнә һәм муниципаль учреждениегә финанс елы дәвамында бюджет чыгымнары классификациясе кодлары буенча җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә. Субсидия муниципаль учреждение заявкасы нигезендә, муниципаль учреждениенең шәхси счетына чыгымнарны түләү өчен бирелә.

11. Муниципаль йөкләмә үтәлмәгән булып исәпләнгән очракта, ирешелмәгән (рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышларны исәпкә алып) муниципаль йөкләмә күрсәткечләренә туры килә торган күләмдә субсидия муниципаль учреждение тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленә кадәр срокта шәһәр бюджетына кире кайтарыла.

Күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күләмен характерлаучы муниципаль йөкләмә күрсәткечләренә, шулай ук күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын характерлаучы муниципаль йөкләмә күрсәткечләренә (әгәр мондый күрсәткечләр муниципаль йөкләмәдә билгеләнгән булса) ирешелмәгән (рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышларны исәпкә алып) очракта, муниципаль йөкләмә үтәлмәгән булып исәпләнә.

## 3 бүлек. Муниципаль йөкләмә үтәлешен контрольдә тотуны, аның үтәлеше турында хисапны гамәлгә ашыру тәртибе

12. Башкарма комитетның тармак органы, шәһәр муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәләрдә алар өчен билгеләнгән таләпләр һәм шартлар үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

13. Муниципаль учреждениеләр хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр срокта Башкарма комитетның тармак органына әлеге нигезнамәгә 2 нче кушымта нигезендә формалаштырыла торган муниципаль йөкләмә үтәлеше турындагы хисапны һәм муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләүне үз эченә алган муниципаль йөкләмәне үтәү нәтиҗәләре турында аңлатма язуын тапшыралар, ә фактик күрсәткечләр зурлыгы пландагыдан тайпылган очракта – тайпылу сәбәпләрен һәм (яки) муниципаль йөкләмәне үтәмәү сәбәпләрен аңлату.

14. Башкарма комитетның тармак органы, әлеге нигезнамәнең 13 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар алынган көннән башлап 15 көн эчендә:

1) тапшырылган хисапларны карап тикшерә;

2) мәгълүматларны һәм исәп-хисапларны тикшерүне гамәлгә ашыра;

3) муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмәләрнең фактик үтәлеше турында җыелма хисап һәм муниципаль йөкләмәләрнең

фактик үтәлеше буенча бәяләмә әзерли һәм аларны финанс идарәсенә җибәрә.

15. Башкарма комитетның финанс идарәсе, муниципаль учреждениеләр эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты чыгымнарын планлаштырганда, шулай ук бюджет өлкәсендә эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен, әлеге нигезнамәнең 14 пунктының 3 пунктчасында каралган җыелма хисаптан һәм бәяләмәдән файдалана.

16. Тиешле муниципаль учреждение бетерелгән яки үзгәртеп оештырылган очракта, муниципаль йөкләмә срогыннан алда туктатыла.

17. Муниципаль учреждение, хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр срокта, хисап елында муниципаль йөкләмә үтәлеше һәм агымдагы финанс елына муниципаль йөкләмә күрсәткечләре турында мәгълүматны интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм «Барс-web. Бюджет ихтыяҗлары мониторингы» программасында һәм http://www.bus.gov.ru сайтында урнаштыра.

## 4 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү тәртибе

18. Башкарма комитетның тармак органы, хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр, муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү критерийларының һәркайсы буенча аерым рәвештә, муниципаль йөкләмә үтәлешен йомгак бәяләү исәп-хисабын гамәлгә ашыра:

1) К1 исәп-хисабы – «муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларыннан файдалану тулылыгы һәм нәтиҗәлелеге» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү;

2) К2 исәп-хисабы – «муниципаль хезмәтләрне кулланучылар саны» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү («муниципаль хезмәтләр саны»);

3) К3 исәп-хисабы – «муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү;

4) $ОЦ_{йомгак}$ исәп-хисабы – һәр муниципаль хезмәт өчен муниципаль йөкләмә үтәлешенә йомгак бәяләү.

19. К1 исәп-хисабы – муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларыннан файдалану тулылыгы һәм нәтиҗәлелеге» бәяләү критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$К1 = (К1.1 + К1.2) / 2, \qquad (1)$$

монда:

К1.1 - шәһәр бюджетының касса үтәлешен исәпкә алып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү;

K1.2 – шәһәр бюджеты акчаларын фактик үзләштерүне исәпкә алып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү.

$$K1.1 = K1касса / K1пл * 100\ \%, \qquad (2)$$

монда:

K1касса – муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджетының касса үтәлеше;

K1пл – муниципаль йөкләмәне үтәүгә бюджет акчаларының пландагы күләме.

$$K1.2 = K1ф(расч.) / K1пл * 100\ \%, \qquad (3)$$

монда:

K1ф(расч.) – муниципаль йөкләмәне үтәү өчен бюджет акчаларының исәп-хисап күләме;

K1пл – муниципаль йөкләмәне үтәүгә бюджет акчаларының пландагы күләме.

$$K1ф(расч.) = K1ф + u, \qquad (4)$$

монда:

K1ф – муниципаль йөкләмәне үтәүгә фактик үзләштерелгән акча күләме;

u – «уңай экономия» суммасы.

20. Муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларын фактик үзләштерүне исәпкә алып, муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларын файдалану тулылыгы һәм нәтиҗәлелеге уңай факторларны исәпкә алып башкарыла.

21. Муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларын тулысынча булмаган үзләштерүнең уңай факторларына (u – «уңай экономия») түбәндәгеләр керә:

1) үткәрелгән конкурентлы сатып алу ысуллары нәтиҗәсендә шәһәр бюджеты акчаларын экономияләү;

2) коммуналь хезмәтләргә түләү буенча шәһәр бюджеты акчаларын экономияләү.

22. «Муниципаль йөкләмәне үтәүгә шәһәр бюджеты акчаларыннан файдалану тулылыгы һәм нәтиҗәлелеге» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү интерпретациясе 1 нче таблица нигезендә гамәлгә ашырыла:

1 нче таблица

| K1 зурлыгы | Бәяләү интерпретациясе |
|---|---|
| K1>100% | муниципаль йөкләмә акчаны экономияләп арттырып үтәлгән |

| | |
|---|---|
| 95% ≤ К1≤ 100% | муниципаль йөкләмә тулы күләмдә үтәлгән |
| 90% ≤ К1< 95% | тулаем алганда, муниципаль йөкләмә үтәлгән |
| К1< 90% | муниципаль йөкләмә үтәлмәгән |

23. К2 исәп-хисабы – «муниципаль хезмәтләрне кулланучылар саны» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү («муниципаль хезмәтләр саны») түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$К2 = К2ф / К2пл * 100 \%, \qquad (5)$$

монда:

К2ф – муниципаль хезмәтләрне кулланучыларның фактик саны (күрсәтелгән муниципаль хезмәтләрнең фактик саны);

К2пл – муниципаль хезмәтләрне кулланучыларның пландагы саны (муниципаль хезмәтләрнең пландагы саны).

24. «Муниципаль хезмәтләрне кулланучылар саны» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү интерпретациясе 2 нче таблица нигезендә гамәлгә ашырыла:

2 нче таблица

| К2 зурлыгы | Бәяләү интерпретациясе |
|---|---|
| К2 > 100% | муниципаль йөкләмә арттырып үтәлгән |
| 95% ≤ К2≤ 100% | муниципаль йөкләмә тулы күләмдә үтәлгән |
| 90% ≤ К2< 95% | тулаем алганда, муниципаль йөкләмә үтәлгән |
| К2< 90% | муниципаль йөкләмә үтәлмәгән |

25. К3 исәп-хисабы – «муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$К3 = \sum_{1\,920}^{N} К3i / N, \qquad (6)$$

монда:

К3i – муниципаль йөкләмәдә күрсәтелгән һәм муниципаль программалар һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартлары нигезендә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын характерлаучы һәр күрсәткеч буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү;

N – конкрет муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль йөкләмәдә күрсәтелгән күрсәткечләр саны.

26. К3i исәп-хисабы – муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфат стандартлары нигезендә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын характерлаучы һәр күрсәткеч буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү түбәндәгечә башкарыла:

$$К3i = К3фi / К3плi *100 \%, \qquad (7)$$

монда:

К3фi – күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын характерлаучы күрсәткечнең фактик зурлыгы;

К3плi – күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын характерлаучы күрсәткечнең пландагы зурлыгы.

27. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты» критерие буенча муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү интерпретациясе 3 нче таблица нигезендә гамәлгә ашырыла:

3 нче таблица

| К3 зурлыгы | Бәяләү интерпретациясе |
|---|---|
| К3 > 100% | муниципаль йөкләмә арттырып үтәлгән |
| 95% ≤ К3≤ 100% | муниципаль йөкләмә тулы күләмдә үтәлгән |
| 80% ≤ К3< 95% | тулаем алганда, муниципаль йөкләмә үтәлгән |
| К3< 80% | муниципаль йөкләмә үтәлмәгән |

28. Һәр муниципаль хезмәт өчен муниципаль йөкләмә үтәлешенә йомгаклау бәясе түбәндәге формулалар буенча билгеләнә::

Муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү өч критерий (К1, К2, К3) буенча башкарылган очракта:

$$ОЦ_{йомгак} = (К1 + К2 + К3) / 3, \qquad (8)$$

монда:

$ОЦ_{йомгак}$ – муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешенә йомгак бәяләү.

29. Муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү ике критерий (К1, К3) буенча башкарылган очракта:

$$ОЦ_{йомгак} = (К1 + К3) / 2 \qquad (9)$$

Һәр муниципаль хезмәт өчен муниципаль йөкләмә үтәлешенә йомгак бәяләү интерпретациясе 4 нче таблица нигезендә гамәлгә ашырыла:

4 нче таблица

| Бәяләү зурлыгы | Бәяләү интерпретациясе |
|---|---|
| $ОЦ_{йомгак} > 100\%$ | муниципаль йөкләмә арттырып үтәлгән |
| $95\% \leq ОЦ_{йомгак} \leq 100\%$ | муниципаль йөкләмә тулы күләмдә үтәлгән |
| $86{,}7\% \leq ОЦ_{йомгак} < 95\%$ | тулаем алганда, муниципаль йөкләмә үтәлгән |
| $ОЦ_{йомгак} < 86{,}7\%$ | муниципаль йөкләмә үтәлмәгән |

30. Муниципаль йөкләмә үтәлешен бәяләү нәтиҗәләре Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан идарә карарлары кабул итү өчен, шулай ук муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүне карап тикшергәндә кулланыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

Килешенде:
Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы
_________________________
«____»___________________

Башкарма комитетның
тармак органы җитәкчесе
_________________________
«____»___________________

Раслыйм:
Башкарма комитет Җитәкчесе
_________________________
«____»___________________

______________________________________________
муниципаль учреждение исеме
__________ елга һәм ______________ еллар план чорына

# МУНИЦИПАЛЬ ЙӨКЛӘМӘ

| | |
|---|---|
| Форма ОКУД буенча | 0506501 |
| Дата | |
| Җыелма реестр буенча код | |
| ОКВЭД буенча | |
| ОКВЭД буенча | |
| ОКВЭД буенча | |

Муниципаль учреждениенең эшчәнлек төре______________________________

1 өлеш. Күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр турында мәгълүмат

2.1. Муниципаль хезмәт исеме:
2. Муниципаль хезмәтләрне кулланучылар булып торучы физик һәм (яки) юридик затлар категорияләре:
3. Муниципаль хезмәтнең сыйфатын һәм (яки) күләмен характерлаучы күрсәткечләр:
1) муниципаль хезмәт сыйфатын характерлаучы күрсәткечләр

<table>
<tr><td rowspan="3">Реестр язуының уникаль номеры</td><td colspan="3" rowspan="2">Муниципаль хезмәт эчтәлеген характерлаучы күрсәткеч (белешмәлекләр буенча)</td><td colspan="2" rowspan="2">Муниципаль хезмәт күрсәтү шартларын (формаларын) характерлаучы күрсәткеч (белешмәлекләр буенча)</td><td colspan="4">Муниципаль хезмәтнең сыйфат күрсәткече</td><td colspan="3" rowspan="2">Муниципаль хезмәтнең сыйфат күрсәткече зурлыгы</td><td colspan="2" rowspan="2">Муниципаль хезмәт сыйфатының билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Күрсәткеч исеме</td><td colspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td rowspan="2">Үтәү срогы</td></tr>
<tr><td>Күрсәткеч исеме</td><td>Күрсәткеч исеме</td><td>Күрсәткеч исеме</td><td>Күрсәткеч исеме</td><td>Күрсәткеч исеме</td><td>Исеме</td><td>ОКЕИ буенча код</td><td>20__ Чираттагы финанс елы</td><td>20__ План чорының 1 нче елы</td><td>20__ План чорының 2 нче елы</td><td>Процентларда</td><td>Абсолют күрсәткечләрдә</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3"></td><td colspan="2"></td><td colspan="4"></td><td colspan="3"></td><td colspan="2"></td></tr>
</table>

2) муниципаль хезмәт күләмен характерлаучы күрсәткечләр:

| Реестр язуының уникаль номеры | Муниципаль хезмәт эчтәлеген характерлаучы күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | | Муниципаль хезмәт күрсәтү шартларын (формаларын) характерлаучы күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | | Муниципаль хезмәтнең сыйфат күрсәткече | | | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткече зурлыгы | | | Түләү күләме (бәясе, тариф) | | | Муниципаль хезмәт сыйфатының билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Күрсәт кеч исеме | Күрсәт кеч исеме | Күрсәт кеч исеме | Күрсәт кеч исеме | Күрсәт кеч исеме | Күрсәт кеч исеме | Үлчәү берәмлеге | | Утәү срогы | 20__ Чираттагы финанс елы | 20__ План чорының 1 нче елы | 20__ План чорының 2 нче елы | 20__ Чираттагы финанс елы | 20__ План чорының 1 нче елы | 20__ План чорының 2 нче елы | Процентларда | Абсолют күрсәткечләрдә |
| | | | | | | | исеме | ОКЕИ буенча код | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |

4. Түләү күләмен (бәясен, тарифын) яисә аны билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар:

| Норматив хокукый акт | | | | |
|---|---|---|---|---|
| төре: | Кабул иткән орган | дата | номеры | исеме |

5. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар:

---

2) муниципаль хезмәтне потенциаль кулланучыларга мәгълүмат бирү тәртибе:

| Мәгълүмат бирү ысулы | Урнаштырыла торган мәгълүмат составы | Мәгълүматны яңарту ешлыгы |
|---|---|---|
| | | |

2 өлеш. Муниципаль йөкләмә турында башка мәгълүматлар

6. Муниципаль йөкләмәне үтәүне срогыннан алда туктату нигезләре (тәртибе һәм шартлары)
1) ______________________________________________________________;
2) ______________________________________________________________.

7. Муниципаль йөкләмәне үтәү (үтәлешне контрольдә тоту) өчен кирәкле башка мәгълүмат

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

8. Муниципаль йөкләмә үтәлешен контрольдә тоту тәртибе

| Контроль формасы | Кабатланып торуы | Башкарма комитетның муниципаль йөкләмә үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы тармак органы |
|---|---|---|
| | | |

9. Муниципаль йөкләмә үтәлеше турында хисапка карата таләпләр

1) муниципаль йөкләмә үтәлеше турында хисап бирүнең кабатланып торуы: ____________________.

2) муниципаль йөкләмә үтәлеше турында хисап бирү сроклары ______________________________.

Муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итү тәртибе турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

## 20 __ елга һәм 20 __ һәм 20 __ еллар план чорына муниципаль йөкләмә үтәлеше турында хисап

Гомумроссия база исемлеге яки федераль исемлек буенча код

| | |
|---|---|
| | |

«__» _________ 20__ ел

Муниципаль учреждение исеме ____________________________

Муниципаль учреждениенең эшчәнлек төре ____________________________

____________________________

____________________________

Кабатланып торуы ____________________________

(муниципаль йөкләмәдә билгеләнгән муниципаль йөкләмә үтәлеше турында хисап бирүнең кабатланып торуы нигезендә күрсәтелә)

| | Кодлар |
|---|---|
| Форма ОКУД буенча | 0506501 |
| Дата | |
| Җыелма реестр буенча код | |
| ОКВЭД буенча | |
| ОКВЭД буенча | |
| ОКВЭД буенча | |
| | |

1 өлеш. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре турында мәгълүматлар <2>

Бүлек _________

1. Муниципаль хезмәтнең исеме________________________________________

| | |
|---|---|
| Гомумроссия база исемлеге яки федераль исемлек буенча код | |

2. Муниципаль хезмәтне кулланучылар категорияләре____________________

3. Муниципаль хезмәт күләмен һәм (яки) сыйфатын характерлаучы күрсәткечләргә фактик ирешү турында мәгълүматлар

3.1. Муниципаль хезмәт сыйфатын характерлаучы күрсәткечләргә фактик ирешү турында мәгълүматлар

<table>
<tr><th rowspan="4">Реестр язуының уникаль номеры</th><th colspan="3" rowspan="2">Муниципаль хезмәт эчтәлеген характерлаучы күрсәткеч</th><th colspan="2" rowspan="2">Муниципаль хезмәт күрсәтү шартларын (формаларын) характерлаучы күрсәткеч</th><th colspan="9">Муниципаль хезмәтнең сыйфат күрсәткече</th></tr>
<tr><th rowspan="3">Күрсәткечнең исеме</th><th colspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="3">зурлыгы</th><th rowspan="3">Рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш</th><th rowspan="3">Рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыштан тайпылу</th><th rowspan="3">Тайпылышның сәбәбе</th></tr>
<tr><th rowspan="2">______ (күрсәткечнең исеме)</th><th rowspan="2">______ (күрсәткечнең исеме)</th><th rowspan="2">______ (күрсәткечнең исеме)</th><th rowspan="2">______ (күрсәткечнең исеме)</th><th rowspan="2">______ (күрсәткечнең исеме)</th><th rowspan="2">исеме</th><th rowspan="2">ОКЕИ буенча код</th><th rowspan="2">муниципаль йөкләмәдә бер елга расланган</th><th rowspan="2">муниципаль йөкләмәдә хисап датасына расланган</th><th rowspan="2">хисап датасына үтәлгән</th></tr>
<tr></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td><td>12</td><td>13</td><td>14</td><td>15</td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

3.2. Муниципаль хезмәт күләмен характерлаучы күрсәткечләргә фактик ирешү турында мәгълүматлар

| Реестр язуының уникаль номеры | Муниципаль хезмәт эчтәлеген характерлаучы күрсәткеч | | | Муниципаль хезмәт күрсәтү шартларын (формаларын) характерлаучы күрсәткеч | | Муниципаль хезмәтнең күләм күрсәткече | | | | | | | | | Түләүнең уртача күләме (бәя, тариф) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | | зурлыгы | | | Рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш | Рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыштан тайпылу | Тайпылышның сәбәбе | |
| | | | | | | | исеме | ОКЕИ буенча код | муниципаль йөкләмәдә бер елга расланган | муниципаль йөкләмәдә хисап датасына расланган | хисап датасына үтәлгән | | | | |
| | ______ (күрсәткечнең исеме) | ______ (күрсәткечнең исеме) | ______ (күрсәткечнең исеме) | ______ (күрсәткечнең исеме) | ______ (күрсәткечнең исеме) | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) ______________ __________ ________________________
(вазыйфасы) (имза) (имза расшифровкасы)

«__» __________ 20__ ел